ГЛАВА
БИЕКТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422665, с. Биектау,
ул. Х.Сафиуллина, дом 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БИЕКТАУ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422665, Биектау,
Х Сафиуллина урамы, 4 йорт

Тел.: (84361) 32-526, факс: (84361) 32-526, эл.адрес: Biek.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

. 2023 елның 31 октябре Биектау авылы № 5

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Яңавыл авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Яңавыл авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2023 елның 23 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
3. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Яңавыл авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Яңавыл торак пунктында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (килешү буенча);
- Яңавыл урам юлларын юл өлешен кышкы чорда кардан чистарту (урамнарны чистарту);
- Яңавыл авылында Киров урамын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Яңавыл т.п. да су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

4. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт;Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

5. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге башлыгы А.Р.Гилазиева